СОВЕТ БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРНАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«02» март 2026 ел** **№23**

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлегенең генераль планын әзерләү зарурлыгы булмау турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының кайбер авыл җирлекләре территориясендә әлеге җирлек территорияләреннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавына һәм социаль-икътисадый үсеш стратегияләренең шулай ук Россия Федерациясен территориаль планлаштыру документлары, Россия Федерациясе субъектын территориаль планлаштыру документлары, Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру документлары белән раслануына бәйле рәвештә федераль һәм региональ әһәмияттәге объектларны, муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектларын әлеге җирлекләр территориясендә урнаштыру каралмавына бәйле рәвештә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Борнак авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлегендә 2026 елның «31» декабренә кадәр генераль планны эшләү зарурлыгы булмавын танырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Законы нигезендә 1 пунктта күрсәтелгән авыл җирлекләрендә җирдән файдалану кагыйдәләре һәм төзелеш проектын әзерләү турында карар кабул итү тәкъдиме белән Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Борнак авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы И.И.Габдуллин